КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

03.09.2024 № 439-П

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2021 нче елның 7 нче декабрендәге № 314-П номерлыбоерыгы белән расланган, Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы Комитеты каршындагы Иҗтимагый совет хакындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 нчы елның 18 нче ноябрендә гамәлгә кергән 906 нчы номерлы «Республика башкарма хакимият органы каршындагы Иҗтимагый совет турында»гы карары нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 нче елның 1 нче июлендәге 1734-р номерлы боерыгы белән расланган, Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрен саклау һәм ныгыту буенча 2024-2026 елларда дәүләт сәясәте нигезләрен гамәлгә ашыру чаралары планын үтәү йөзеннән боерам:

Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитеты каршындагы Иҗтимагый совет турындагы 2021 нче елның 7 нче декабрендә гамәлгә кергән боерык белән расланган «Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитеты каршындагы Иҗтимагый совет турында»гы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Министрлык, Дәүләт комитеты, ведомство каршында» сүзләрен «республика башкарма хакимияте органы каршында» сүзләре белән алмаштырырга;

1.3 нче пункттагы «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләре белән алмаштырырга;

2.2 нче пунктка түбәндәге эчтәлектәге алтынчы абзацны өстәргә::

«Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрен, мәдәниятен һәм тарихи хәтерен яклау.»;

5.12 нче пунктта «һәм башка белгечләр» сүзләрен«, башка белгечләр һәм гражданнар " сүзләренә алмаштырырга»;

5.14 нче пунктта «техник һәм оештыру ягыннан тәэмин итү» сүзләрен «оештыру-техник яктан тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга.

6.6 нчы пунктның икенче абзацына «әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тәкъдимне алган көннән башлап, эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә» сүзләрен өстәргә;

6.7 нче пунктның икенче абзацына «әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тәкъдимне алган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә» сүзләрен өстәргә;

6.8 нче пунктның икенче абзацына «әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тәкъдимне алган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә» сүзләрен өстәргә.

Рәис И.Н. Гущин